**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 70-33 25 сентябрь 2017 ел

Туйкә авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Туйкә авыл җирлеге Уставының 12 маддәсе, Туйкә авыл җирлеге башкарма комитетының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Туйкә авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 65-32 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә үзарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
“Сез, Туйкә авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 300 сум күләмендә үзарасалым җыю белән килешәсезме. Үзарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Үзарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
1) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (Туйкә авылында Бөек Ватан сугышы геройлары истәлегенә төзелгән һәйкәлгә капитал ремонт ясау);
2) авыл эчендәге юлларны кышкы чистарту;
3) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (Туйкә, Камышлы Күл авылларының су линияләрен ремонтлау, су линияләренең техник документациясын ясату);
4) ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (Карамалы-Елга авылы зиратының коймасын алыштыру, ритуаль йортын ремонтлау)

РИЗА КАРШЫ ”

3.Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис Закирова Р.Р.